№4 май, 2018 ел

# Гимназия сулышы

***25 нче гимназия укучылары газетасы***



## Бүгенге санда

- “Гимназия – сыйфатлы белем гаранты”,  9нчы Гсыйныфы укучысы Якупова Гүзәл язмасы, 1-бит
- “Җиңү бәйрәме”, гимназиядә узган бәйрәмнән репортаж
- “Мин татарча сөйләшәм!”, 7нче Г сыйныфыннан Хуҗҗәтов Гадел язмасы, 4-бит.
- “ Яшь язучылар бәйгесе”, 9нчы Г сыйныфы укучысы Хәйруллина Диләрә язмасы,4-бит
- “Соңгы кыңгырау” бәйрәме, 7нче В сыйныфы укучысы Фәйзулин Әмир репортажы
- “Кызыклы экскурсия ”, 5нче Г сыйныфыннан Мирхазиянов Әмир хәбәре.
- “Ура, каникуллар!”, 6 нчы Д сыйныфы укучысы Качаева Диана язмасы

**Гимназия – сыйфатлы белем гаранты**

Уку елы ахырында традиция буенча гимназиядә фәнни олимпиадаларда җиңүче укучыларны тантаналы бүләкләү чарасы үткәрелде.



Рус теле һәм әдәбияты фәне буенча Бөтенроссия олимпиадасының муниципаль этабы призерлары һәм җиңүчеләре –Данилова Дарья (6б), Пшеворская Валерия (5б), Файзрахманова Рузилә (8б), Хрущева Дарья (9а); математика ,биология, табигать белеме фәннәре буенча – Коробейников Кирилл (6г), Сергеев Арсений (5а), Закирова Тамила (4а), Мөхәммәтшина Амира (3 а), Халикова Арина (3 б), Захаров Александр (3б), Закирова Рушания (8б), Иванова Анастасия( 7б), Джураев Акмаль (3д), Шәрәфетдинова Алия (5 в), Сергеев Арсений (5 а), Пшеворская Валерия (5 б), Носкова Диана (5 б), Макаршин Тимофей ( 6 а); тарих, җәмгыять белеме, дөньяви рәсем сәнгате фәннәре буенча- Хрущева Дарья (9 а), Закирова Рушания(8 б), Иванова Таисия ( 7 б), Клевлина Карина (8 б), Тома Анастасия (7 б), Данилова Дарья (6 б), чит телләр һәм туган тел буенча – Закирова Рушания ( 8б), Фәйзрахманова Рузилә (8 б), Фазлиев Раиль (5 б), Ординарцев Егор (8 в), Яркеев Илья (6 д), Николаев Дмитрий (6 а), Хамзина Айгөл (11а), Сергеев Арсений (5 а), Фазлиев Раиль (5б), Шәрәфетдинова Алия (5 В), Әлеге укучыларның остазларына , үз эшенең остасы булган укытучыларга, күп мактау сүзләре әйтелде. Алар - Абдулвәлиева Х.Ф., Кузьмина Г.А., Казакова А.Ф., Егорова С.А., Долгашева В.В., Дмитриева Л.О., Мәүләветдинова Л.А., Федорова Н.И., Миронова Н.В., Суханова А.П., Бердникова М.В., Шәрәфетдинова О.Н., Игнатьева Е.В., Вәлиева Л.Р., Ибраһимова Э.Ш., Ефремова Л.В., Пшеворская С.Г., Семенова В.П., Коновалова Н.З., Крюкова Р.В., Кальмаева Н.В., Кәлимуллина Д.А., Гарипова Р.Р., Осипова Г.Т. Чыннан да, укытучыларыбыз барлык сәләтләрен, методик осталыкларын, күңел җылысын балаларга биреп эшли. Гимназия - профессионаллар территориясе, дип әйтү урынлы булыр, минемчә.

Гимназиянең “Иң яхшы укучылары” н аеруча билгеләп үтәсе килә. 2017-2018 нче уку елында укуда иң яхшы нәтиҗәләр өчен рус теле һәм әдәбияты буенча Бөтенроссия олимпиадасының Түбән Кама муниципаль районы этабында, Татарстан Республикасы мәктәп укучылары арасында, Бөтенроссия мәктәп укучылары арасында беренче урын алган

9 А сыйныфы укучысы Хрущева Дарья ( укытучысы Казакова А. Ф.) һәм математика буенча Бөтенроссия олимпиадасының муниципаль этабында призер, шулай ук Республика этабында призер, башлангыч сыйныфлар өчен “Математика марафоны” Республика олимпиадасында җиңүче булган, 4 А сыйныфы укучысы Закирова Тамила ( укытучысы Мәүләветдинова Л.А.) “ Ел укучысы” титулына һәм исемле стипендиягә ия булдылар. Яңа җиңүләргә ирешүегезне телибез! Уңышлар юлдаш булсын, сезгә, кадерле укучылар ! Якупова Гүзәл, 9 г сыйныфы

**Гимназиядә “ Җиңү бәйрәме”**

8 майда гимназиядә Бөек Ватан сугышы тәмамлануының 73 еллыгына багышланган бәйрәм концерты булды.



Килгән кунаклар - ветераннар, тыл хезмәтчәннәре - “сугыш чоры” балалары гимназия укучыларының дәртле биюләрен карадылар, җырларын тыңладылар. Ә инде укучылар һәм укытучылар сугышта катнашкан әби-бабайларының, туганнарының фоторәсемнәрен тотып чыккач, чарада катнашучы һәр кешенең күзләре яшьләнде. Әйе, аяусыз сугыш бер гаиләне дә читләп үтмәгән шул. Күпме туганнарыбыз сугыш кырларында мәңгегә ятып калган. Соңыннан ветераннар әңгәмәне чәй табыны артында дәвам иттеләр.



**Мин татарча сөйләшәм!**

Апрель аенда Республика күләмендә оештырылган “Мин татарча сөйләшәм !”акциясендә безнең гимназия укучылары да актив катнашты. Сыйныф сәгатьләрендә укучылар татар телендә аралаштылар. 7 нче, 8 нче сыйныф укучылары “ Пятёрочка” сәүдә үзәгендә сатучылар белән татарча сөйләштеләр. Әлеге акциянең максаты халыкны, бигрәк тә яшьләрне, мәктәп укучыларын татар телендә сөйләшергә өндәү иде. Чөнки татар теле-дөньяда иң киң таралган төрки телләрнең берсе. Тукай теле...Дәрдемәнд, Җәлил, Туфан теле...






**Яшь язучылар бәйгесе**

Ел саен шәһәр һәм район укучылары арасында якташыбыз, күренекле халык шагыйре, биш дистәдән артык китап авторы Разил Исмәгыйль улы Вәлиев премиясенә яшь язучылар бәйгесе үткәрелә. 20 ел эчендә әлеге конкурста шәһәр һәм район мәктәпләрендә белем алучы мең ярымнан артык укучы бала үз көчен сынаган. Безнең гимназиядән өч укучы Фәйзуллин Әмир (7в), Сәйфуллина Камилә (10а), Шәрәфетдинова Алия (5в) үзләренең иҗади эшләрен җибәргәннәр иде. Май аенда конкурста җиңүчеләрне һәм катнашучыларны бүләкләү кичәсе булып үтте.

Сәйфуллина Камилә ( укытучысы Осипова Г.Т.) “ Әкият сөйлим сезгә”номинациясендә җиңүче Дипломы белән бүләкләнде. Фәйзуллин Әмир (укытучысы Шарапова Н.Н.) һәм Шәрәфетдинова Алия (укытучысы Гыймранова З.М.) сертификат белән бүләкләнделәр.





**“ Соңгы кыңгырау” бәйрәме**

24 май көнендә гимназиянең 11А сыйныфының 25укучысы һәм 9 нчы А, Б, В, Гсыйныфларының 96 укучысы өчен “Соңгы кыңгырау” бәйрәме уткәрелде. Түбән Кама муниципаль район советының хокук бүлеге директоры урынбасары Зарифуллин Р.Т. һәм гимназия директоры Гаранина С.В. чыгарылыш сыйныф укучыларына дәүләт имтиханнарын уңышлы биреп, үзләре сайлаган уку йортларына керүләрен теләделәр. Укучылар үз чиратында ныклы белем биргән укытучыларга, тантанада катнашучы әти-әниләренә рәхмәт хисләрен җиткерергә ашыктылар.










**Сау бул, гимназия**!

Кошлар да бер шулай таралалар.
Сау бул инде, туган оябыз!
Офыкларга карап очар өчен
Иңнәрдә без канат тоябыз.
Зур юлларга безне чыгардың син,
Күңелләргә бирдең омтылыш.
Соңгы кыңгырау булсын беренчесе,
Син каршыла безне, зур тормыш!

**Кызыклы экскурсия**



Кичке шәһәр буенча экскурсия турында беләсезме ? Аны фонарьчы Фаролеро уткәрә. Өстеңә плащ ябынасың , колакчын киясең дә әкиятче артыннан яңартылган Кама яры буеннан атлыйсың.



Кулына фонарь тотып, аксый төшеп, авырлык белән атлаучы әкиятчене тыңлап барганда, күңелне могҗизалы серлелек биләп ала... Кичке караңгылыкта, Кызыл Чишмә бистәсендә фонарьчы Фаролеро белән бер сәгатькә якын йөрдек : бертуган сәүдәгәр Стахеевлар турында, Түбән Камада яшәгән рәссам Ә.Фәтхетдинов турында күп кызыклы мәгълүмат ишеттек. Бу кичке экскурсия безнең өчен яңалык булды. Аны оештырган сыйныф җитәкчесе Басыйрова Нина Иван кызына һәм әти-әниләребезгә зур рәхмәт әйтәсе килә!

**Ура, каникуллар!**

Менә уку елы да тәмамланып килә. Тиздән укучыларның зарыгып көткән җәйге ялы башлана. Каникулны кызыклы һәм шул ук вакытта файдалы итеп уздыру өчен балалар өчен сәламәтлек һәм ял лагерьлары эшләячәк. Шәһәр янындагы “Кама”, “Юность”, “Олимпиец”, “Зәңгәр күл”, “Чайка” лагерьлары балаларны кабул итәргә әзер инде. Кояшлы матур җәй айларында күңелле яллар телибез, сезгә , кадерле укучылар !



Редактор: Хуҗҗәтов А.
Проект җитәкчесе: Шарапова Н.Н.